**СОВЕТ**
**Кулегашского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Күләгәш авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021 с. Кулегаш № 13-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы, Татарстан Республикасының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге Советының кайбер карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» 2021 елның 16 августындагы 11-1 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгәш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 29 мартындагы 12-6 номерлы карары.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге Советының «Санлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2021

елның 16 августындагы 11-2 номерлы карары 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының портал составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Күләгәш авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында элеп халыкка чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы                                        Ю.Н.ВАСИЛЬЕВ